**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав., 23740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.r

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　________

Мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирүне гамәлгә ашыручы Актаныш муниципаль районы мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын карау, тәрбияләү һәм туклану өчен түләүдән азат итү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Актаныш муниципаль районы мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләсенең балаларын караган, тәрбияләгән һәм туклануы өчен өчен ата-аналардан (законлы вәкилдән) алына торган түләүдән азат итәргә.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының МКУ “Мәгариф идарәсе”нә :

2.1. 1 пунктта күрсәтелгән ташламаны, хәрби комиссариатның өлешчә мобилизация кысаларында, белем бирү оешмасында укучы тәрбияләнүченең ата-анасын (законлы вәкилен) хәрби хезмәткә чакыру турындагы белешмәсе нигезендә бирергә;

2.2. өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта, ташламаларның гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максаты белән хәрби комиссариат белән хезмәттәшлектә торырга.

3. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Актаныш муниципаль районының мәгариф оешмаларында өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренең укучы балаларын карауны һәм тукландыруны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән гражданнарның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт үткән вакытта барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.М.Шакировага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы Р.А.Ильясов